РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕЧЕКМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ЧАКМАК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

*423993, РТ, Муслюмовский район. с. Большой Чекмак, ул. Центральная 1,*
Bchak.Mus@tatar.ru *тел. (8-85556) 3-10-97*

с. Большой Чекмак «5» март 2021 ел

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ № 5** **КАРАР № 5**

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Олы Чакмак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Олы Чакмак авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәреш кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 7 февраль 3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру Тәртибенә түбәндәгеләрне өстәп, үзгәреш кертергә:

**1.1. 10 пунктның 2 абзацын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән дәвам итәргә:** «һәм мәҗбүри рәвештә салым, җыемнар, пенялар һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычлар булмау турында Россия Федераль салым хезмәтеннән белешмә.».

**1.2. 10 пунктны 3 абзац өстәргә:** «мөрәҗәгать итүче 10 пунктның 2 абзацында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, җирле үзидарә органы ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмәләрне мөстәкыйль рәвештә соратып ала».

**1.3. 20 пунктны түбәндәге 4 пунктча белән тулыландырырга:** «4) законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Олы Чакмак авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Габидуллин И.М.**